**Татарстан Республикасы һәм Кырым Республикасы арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турында**
**КИЛЕШҮ**

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов йөзендә Татарстан Республикасы бер яктан һәм Кырым Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Кырым Республикасы Башлыгы, Кырым Республикасы Министрлар советы Рәисе Аксёнов Сергей Валерьевич йөзендә Кырым Республикасы икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып,

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясенең һәм Якларның башка хокукый актларына нигезләнеп,

үз хокукларын һәм вәкаләтләрен Россия Федерациясенең тигез хокуклы субъектлары буларак гамәлгә ашырып,

тотрыклы һәм озак вакытка исәпләнгән ике яклы элемтәләрне үстерүдә үзара кызыксыну күрсәтеп, Якларның социаль-икътисадый үсешендә, Татарстан Республикасы һәм Кырым Республикасы территорияләрендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектлары арасында базар мөнәсәбәтләрен үстерү өчен уңай шартлар тудыруда үзара кызыксынганлык принципларына нигезләнеп,

түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

**1 статья**

Яклар инде булдырылган сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни элемтәләрне дуслык, ышаныч һәм үзара хөрмәт рухында үстерә, тигезлек, партнерлык һәм үзара файда нигезендә, аның өчен тиешле оештыру, икътисадый, хокукый һәм башка кирәкле шартлар тудырып, хезмәттәшлек итә.

**2 статья**

Яклар уртак проектларны эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтә, Татарстан Республикасы һәм Кырым Республикасы территорияләрендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектларының федераль һәм төбәк программаларын гамәлгә ашыруда катнашуына ярдәм итә.

**3 статья**

Яклар фәнни-техник, икътисадый һәм хокукый мәгълүмат алмаша, Татарстан Республикасы һәм Кырым Республикасы территорияләрендә

эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектлары җитештерә торган продукциянең сатылуына һәм уртак күргәзмәләр, ярминкәләр уздыруга булышлык күрсәтә.

**4 статья**

Яклар сәламәтлек саклау, фән, мәдәният, мәгариф, халыкны социаль яклау, гаилә һәм гендерлык сәясәте, демографик үсеш, физик культура һәм спорт, яшьләр сәясәте, хезмәт мөнәсәбәтләре, халыкны эш белән тәэмин итү, миграция, эшкуарлык эшчәнлеге, урман хуҗалыгы, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә хезмәттәшлек итә.

**5 статья**

Яклар ике яклы чаралар уздырганда Татарстан Республикасының һәм Кырым Республикасының туристлык өлкәсендә мөмкинлекләре турында реклама материаллары, мәгълүмати материаллар алмашу юлы белән туристлык өлкәсендә хезмәттәшлек урнаштыруга ярдәм итә.

**6 статья**

Яклар җир асты байлыкларыннан файдалану һәм транспорт комплексы өлкәләрендә мәгълүмат алмашуны оештыру юлы белән хезмәттәшлек итә.

Яклар тимер юл, һава, автомобиль һәм су транспортын, шулай ук пассажирлар йөртүне үстерү мәнфәгатьләрендә дәүләт-хосусый партнерлык проектларын үтәү буенча тәҗрибә алмашуны гамәлгә ашыра.

Яклар халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшырту максатларында транспортның барлык төрләрендә пассажирлар йөртү өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итүгә кагылышлы үзара методик ярдәм күрсәтә.

**7 статья**

Яклар бер-берсенә хокукый ярдәм күрсәтә, Якларның дәүләт хакимиятенең башкарма һәм закон чыгару органнары арасында элемтәләрен киңәйтүгә актив ярдәм күрсәтә, закон чыгару һәм хокуклардан файдалану эшчәнлеге, коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә тәҗрибә алмаша.

**8 статья**

Яклар Россия Федерациясенең дәүләт программаларын, Татарстан Республикасы һәм Кырым Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында мәгълүмати-коммуникация технологияләрен үстерү мәсьәләләре буенча, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне электрон рәвешкә күчергәндә дә, тәҗрибә уртаклаша.

**9 статья**

Яклар энергия ресурсларыннан сакчыл файдалану, кече энергетиканы үстерү, энергиянең яңара торган чыганакларын куллану, инженерлык инфраструкурасы, торак төзелеше һәм электр энергетикасын үстерү программаларын эшләү өлкәсендә мәгълүмат һәм тәҗрибә алмаша.

**10 статья**

Яклар мәдәният, сәнгать, кинематография, Татарстан Республикасы һәм Кырым Республикасы территорияләрендә театр-концерт һәм иҗат коллективлары, музыкаль төркемнәр гастрольләрен, рәсем сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һәм фотография күргәзмәләрен, фестивальләр, очрашулар, конкурслар, дискуссияләр һәм башка чараларны оештыру өлкәсендә булдырылган багланышларны һәм элемтәләрне ныгытуга һәм үстерүгә ярдәм итә.

Яклар Татарстан Республикасы һәм Кырым Республикасы китапханәләр системасы арасында үзара файдалы хезмәттәшлеккә, шулай ук китапханә эше өлкәсендә тәҗрибә уртаклашуга ярдәм итә.

Яклар мәдәният, сәнгать, кинематография өлкәсендә фәнни-методик эшне гамәлгә ашыра, мәдәни мирас объектларын саклап калу, файдалану һәм популярлаштыруга ярдәм итә.

Яклар мәдәният, сәнгать, кинематография өлкәсендә фәнни-методик эшне гамәлгә ашыра, мәдәни мирас объектларын саклап калу, файдалану һәм популярлаштыру өлкәсендә, шул исәптән әлеге өлкәгә идарә итү системасын камилләштерү эшендә заманча инновацияле технологияләр файдалану буенча да, мөнәсәбәтләрне җайга салучы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру эшенә кагылышлы мәгълүмат һәм тәҗрибә алмаша.

**11 статья**

Яклар Татарстан Республикасы һәм Кырым Республикасы халкын һәм территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә хезмәттәшлек итә, янгынга каршы куркынычсызлыкны һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итә.

**12 статья**

Әлеге Килешү Яклар тарафыннан хезмәттәшлекнең тәгаен өлкәләрендә төбәкара программалар, проектлар һәм чаралар планнары эшләү өчен нигез булып тора.

**13 статья**

Әлеге Килешүнең нигезләмәләрен гамәлгә ашыруга ярдәм итү һәм Яклар тарафыннан әлеге Килешүгә нигезләнеп кул куелган карарлар, шартнамәләр, чаралар планнары үтәлүе барышын тикшереп тору

максатларында Яклар ике яклы сөйләшүләр уздыра һәм уртак эш төркемнәре төзи ала.

Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы һәм Кырым Республикасы территорияләрендә вәкиллекләр төзи ала.

**14 статья**

Әлеге Килешү Якларның һәр икесенең өченче як белән төзелгән килешүләрендә (шартнамәләрендә) билгеләнгән йөкләмәләренә кагылмый.

Әлеге Килешүне гамәлгә ашырганда аның нигезләмәләрен төрлечә шәрехләү һәм куллану мөмкин булса, мондый хәлләрдән чыгу Яклар тарафыннан үзара консультацияләр һәм сөйләшүләр уздыру юлы белән хәл ителә.

**15 статья**

Һәр кайсы риза булган очракта, Яклар Килешүне үзгәртә ала. Барлык үзгәрешләр аерым өстәмә килешүләр нигезендә рәсмиләштерелә.

Килешү аңа Яклар кул куйган көннән үз көченә керә һәм 5 (биш) ел дәвамында гамәлдә була. Әгәр дә Якларның берсе аның вакыты чыкканга кадәр өч айдан да соңга калмыйча, башка Якка үзенең әлеге Килешүне өзәргә теләве хакында язма рәвештә белдермәсә, Килешү аннан соңгы һәр елга үзеннән-үзе озайтыла.

Казан шәһәрендә 2014 елның «15» ноябрендә бер үк төрле көчкә ия ике нөсхәдә, һәрберсе рус, татар, Кырым татарлары һәм украин телләрендә, һәр Як өчен берешәр нөсхәдә башкарылды.

Терминнарның мәгънәсе төрлечә аңлатылган яисә нинди дә булса каршылык килеп чыккан очракта рус телендәге текст өстенлекле була.

**Татарстан Республикасы өчен**

**Татарстан Республикасы Президенты**

_______________ **Р.Н. Миңнеханов**

**Кырым Республикасы өчен**

**Кырым Республикасы Башлыгы, Кырым Республикасы Министрлар советы Рәисе**

_______________ **С.В. Аксёнов**

17.11.2014
№ 26